ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.08.2019 ел Баулы шәһәре №230

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесенең 2012 елның
1 февралендә кабул ителгән 28нче
номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы мәнфәгатьләрендә
ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату
тәртибенә үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

2018 елның 3 августында кабул ителгән «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына линияле объектларны урнаштыруны гадиләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында»гы №341-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статья нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 1 февралендә кабул ителгән 28нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Сервитут Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү, шулай ук, җир участокларын тартып алмыйча, җирле халыкның ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында билгеләнергә мемкин (ачык сервитут).»;

1.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Ачык сервитут түбәндәге максатта билгеләнә:

1) җир участогы аша транспортта яисә җәяү үтү, шул исәптән гомуми файдаланудагы су объекты янына һәм аның яр буе полосасына гражданнарның ирекле үтүен тәэмин итү максатларында;

2) җир участогында ызанлау билгеләрен, дәүләт геодезик челтәрләренең геодезия пунктларын, гравиметрик пунктларны, нивелир пунктларын һәм аларга керү юлларын урнаштыру өчен;

3) җир участогында дренаж эшләре үткәрү өчен;

4) су объектларыннан һәм сулыклардан су ресурсларын алу өчен;

5) җир участогы аша авыл хуҗалыгы хайваннарын үткәрү өчен;

6) печән чабу, авыл хуҗалыгы хайваннарын җир участогында билгеләнгән тәртиптә, җирле шартларга һәм гореф-гадәтләргә туры килә торган срокларда көтү өчен;

7) ау, балыкчылык, аквакультура (балык үрчетү) максатларында җир участогыннан файдалану өчен;

8) Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.37. статьяда каралган максатларда җир участогыннан файдалану өчен.»;

2.1. пунктта «карар» сүзен «карар»га алмаштырырга;

2.2. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Ачык сервитутны билгеләү инициатолары - Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары, хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар (әгәр ачык сервитут билгеләү аларның эшен һәм тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булса), шулай ук, җир участогыннан файдалану хокуклары Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районы мәнфәгатьләрендә фактта файдалану нәтиҗәсендә чикләнгән булса, җир участоклары милекчеләре, җир хуҗалары һәм җирдән файдаланучылар.»;

2.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Ачык сервитут билгеләү турындагы үтенеч язуында күрсәтелгән булырга тиеш:

1) мөрәҗәгать итүченең исеме һәм урнашу урыны, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турындагы язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры;

2) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37. статьясы нигезендә, ачык сервитутны билгеләү максаты;

3) ачык сервитут алу срогы;

4) җир кишәрлегеннән (аның өлешеннән) һәм (яки) анда урнашкан күчемсез милек объектыннан, рөхсәт ителгән файдалану тере нигезендә, ачык сервитут билгеләнә торган эшчәнлекне тормышка ашыруга бәйле рәвештә, файдалану мөмкин булмаган яисә шактый кыенлашкан вакыт. Күрсәтелгән срокка инженер корылмасын төзү, реконструкцияләү, капиталь яки агымдагы ремонтлау вакыты кертелә;

5) ачык сервитут билгеләү зарурлыгын нигезләү;

6) күрсәтелгән инженерлык корылмасын реконструкцияләү яисә эксплуатацияләү өчен ачык сервитут билгеләү турында үтенеч язуы бирелгән булса, мөрәҗәгать итүченең инженерлык корылмасына хокукы булуын раслаучы күрсәтмә;

7) җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар ечен тартып алуга бәйле рәвештә, күчерелә торган инженерлык корылмасына хокук иясе турында белешмәләр (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән инженерлык корылмасы милекчесе булмаса);

8) ачык сервитут билгеләү турында гариза бирелгән җир участогының кадастр номерлары (алар булган очракта), адресы яки мондый җир участогының урнашу урынының башка тасвирламасы;

9) мерәҗәгать итүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы.».;

2.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Ачык сервитут билгеләү турындагы үтенеч язуына Россия Федерациясе Җир кодексының 39.41. статьяның 5 пункты нигезендә документлар теркәлә.

Ачык сервитут билгеләү турындагы үтенеч язуы һәм аңа кушып бирелә торган документлар, мерәҗәгать итүче теләге буенча, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар ечен җир участокларын алу турындагы үтенеч язуы ечен билгеләнгән тәртиптә һәм ысул белән шәхсән үзе тарафыннан яисә почта элемтәсе аша кәгазьдә йә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, электрон документ рәвешендә тапшырылырга мөмкин.

Ачык сервитут билгеләүгә вәкаләтле орган, ачык сервитут билгеләү турында үтенеч язуы кергән көннән алып биш эш көне эчендә, түбәндәге шартлар булганда, кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, аны тикшермичә кире кайтара:

1) үтенечнамә үтенеч язуында күрсәтелгән максатлар өчен ачык сервитут билгеләү өчен вәкаләтле органга тапшырылмаса;

2) мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе Җир кодексының 39.40. статьясында каралган зат буласа;

3) ачык сервитут билгеләү турында үтенеч язуы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37. статьясында каралмаган максатларда бирелсә;

4) ачык сервитут билгеләү турындагы үтенеч язуына Россия Федерациясе Җир кодексының 39.41. статьяның 5 пунктында каралган документлар беркетелмәсә;

5) ачык сервитут билгеләү турындагы үтенеч язуы һәм аңа кушып бирелгән документлар Россия Федерациясе Җир кодексының 39.41. статьяның 4 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә.

Әгәр ачык сервитут билгеләү турында гариза Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37. статьяның 1, 2, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән максатларда бирелгән булса, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма

комитеты) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.42 статьясындагы 3-8 пунктларында каралган тәртиптә, җир участоклары ияләрен ачыклау тәэмин ителә.»;

2.7. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән билгеләнә.»;

2.8. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Башкарма комитетның ачык сервитутны билгеләү турындагы карарында түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) ачык сервитутны билгеләү максаты;

2) кемнең ачык сервитут билгеләү турында гаризасы нигезендә карар кабул ителүе турында белешмә;

3) дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын тартып алуга бәйле рәвештә күчерелә торган инженерлык корылмасының милекчесе турында белешмә (ачык сервитут күрсәтелгән инженерлык корылмасын реконструкцияләү максатларында билгеләнсә һәм ачык сервитут иясе күрсәтелгән инженер корылмасының милекчесе булмаса);

4) ачык сервитут билгеләнә торган җир участогының кадастр номерлары (алар булганда), урнашу урыны, адресы яки тасвирламасы;

5) ачык сервитут срогы;

6) җир участогыннан (аның өлешеннән) һәм (яки) анда урнашкан күчемсез мелкәт объектыннан, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә, сервитутны тормышка ашыруга бәйле рәвештә, файдалану мөмкин булмаган яки шактый кыенлашкан вакыт (мондый срок булганда);

7) документларны раслау турындагы карар реквизитлары яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.41. статьясының 2 пунктында каралган документлар реквизитлары (ачык сервитут билгеләү турында карар күрсәтелгән документлар нигезендә кабул ителгән булса);

8) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарны билгеләү тәртибен һәм мондый зоналар чикләрендә җир участокларына хокукларны чикләүне билгели торган норматив актлар реквизитлары (ачык сервитут территорияләрдән файдалануның аерым шартлары булган зоналарны билгеләүне таләп итә торган инженерлык корылмасын урнаштыру максатларында билгеләнсә);

9) ачык сервитут өчен түләү исәпләү һәм түләү кертү тәртибе (муниципаль милектә булган һәм гражданнарга яисә юридик затларга бирелмәгән җирләргә яисә җир участокларына карата ачык сервитут билгеләгән очракта);

10) эшчәнлек терен тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнеп, эшчәнлекне тормышка ашырганда эш башкару графигы (муниципаль милектә булган һәм гражданнарга яисә юридик затларга бирелмәгән җирләргә яки җир участокларына карата ачык сервитут билгеләнгәндә);

11) ачык сервитут иясе җир участогын рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы халәткә китерергә, ачык сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын Россия Федерациясе Җир кодексының 39.50. статьясындагы 8 пунктында каралган срокларда сүтәргә бурычлы икәнлегенә күрсәтмә.»;

2.9. пунктта беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ачык сервитут, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.25. статьяның 4 пунктында каралган сервитутлардан тыш, дәүләт теркәвенә алынырга тиеш. Ачык сервитутлар турында белешмәләр Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелә.»;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пунктчасында күрсәтелгән объектны җир участогында урнаштыру Россия Федерациясе Җир кодексының 39.44. статьясы 1 пункты 4 пунктчасында каралган сроктан артып киткән вакыт эчендә җир участогыннан файдалануга (рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә) мөмкинлек бирмәсә яисә аны куллануда җитди кыенлыклар тудырса, гражданның яки юридик затның җир участогында күрсәтелгән корылма ачык сервитут шартларында урнаштырылмый. Бу очракта күрсәтелгән корылма, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 һәм 56.3 статьяларында каралган шартларны үтәп, җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алганнан соң урнаштырылырга мөмкин.»;

2.12. өченче абзацта «карар» сүзен «карар»га алмаштырырга;

3.1.-3.5. пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

«Ачык сервитут өчен түләүне билгеләү һәм түләү тәртибе» карарына 2нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Мелкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров